| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОКУВАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ КУАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел Иске Куак ав. № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә 17 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?

- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру, су чыгаруны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру - суүткәргечне ремонтлау һәм алмаштыру.

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге-төзекләндерү һәм вак таш салу.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге караны Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 нчы йорт, Зеленая урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» (http://leninogorsk.tatarstan.ru) бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Куак авыл җирлеге башлыгы И.Н. Сушкова